**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 9 октябрендәге 3397 номерлы карары**

**Казан шәһәренең «“Возрождение” ярдәм үзәге» муниципаль автоном учреждениесе тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны билгеләү тәртибен раслау турында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 19 ноябрендәге 10406 номерлы «Казан шәһәре муниципаль учреждениеләренә карата муниципаль биремне формалаштыру һәм муниципаль биремне үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү тәртибе турында»гы карарының 3 пунктын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 69.2 һәм 78.1 статьялары, 2017 елның 10 июлендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына алкоголь, наркотик яисә башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 10 сентябрендәге 759 номерлы «2025 елга, 2026 һәм 2027 елларның план чорына алкоголь, наркотик яисә башка төрле токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәтләр күрсәтү бәясе нормативын раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. «“Возрождение” ярдәм үзәге» муниципаль автоном учреждениесе тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны билгеләү тәртибен расларга (кушымта).

2. Әлеге карарның йогынтысы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 9 октябрендәге
3397 номерлы карарына
кушымта

**«“Возрождение” ярдәм үзәге» муниципаль автоном учреждениесе тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны билгеләү тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен «Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесе гамәлгә ашыра торган «“Возрождение” ярдәм үзәге» муниципаль автоном учреждениесе (алга таба – Учреждение) тарафыннан хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны билгеләүнең әлеге тәртибе (алга таба – Тәртип) Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 19 ноябрендәге 10406 номерлы «Казан шәһәре муниципаль учреждениеләренә карата муниципаль биремне формалаштыру һәм муниципаль биремне үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү тәртибе турында»гы карарының 3 пункты, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 69.2 һәм 78.1 статьялары, 2017 елның 10 июлендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына алкоголь, наркотик яисә башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 10 сентябрендәге 759 номерлы «2025 елга, 2026 һәм 2027 елларның план чорына алкоголь, наркотик яисә башка төрле токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәтләр күрсәтү бәясе нормативын раслау турында»гы карары нигезендә эшләнгән.

1.2. Муниципаль бирем кысаларында күрсәтелә торган торган, шулай ук муниципаль учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган (башкарыла торган) һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 5 сентябрендәге 638 номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) торган һәм бюджетара мөнәсәбәтләр булдырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәтләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында»гы карары белән раслаган Татарстан

Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалашканда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлегенә кертелгән «Алкоголь, наркотик яисә башка төрле токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру» (уникаль номер/хезмәт күрсәтү коды: 880000Р.16.1.НЕ15АА67000) муниципаль хезмәте өчен хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар өч елга раслана.

1.3. Хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар чираттагы финанс елына һәм план чорларына учреждение тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итү күләмен исәпләгәндә кулланыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар бәянең база нормативы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Министрлар Кабинетының 2024 елның 10 сентябрендәге 759 номерлы «2025 елга, 2026 һәм 2027 елларның план чорына алкоголь, наркотик яисә башка төрле токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәтләр күрсәтү бәясе нормативын раслау турында»гы карары белән расланган бәянең база нормативларына төзәтү коэффициентлары нигезендә муниципаль биремдә билгеләнгән хезмәт күрсәтү күләме күрсәткече берәмлегенә исәпләнә.

1.5. Хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар күрсәткечләре учреждениенең «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

## II. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү

2.1. J хезмәтләр башкаруга норматив чыгымнар (N) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$N = (S/V) + (D/V),$$ монда

N – хезмәт күрсәтү чыгымнары нормативы, койка-урын өчен сум;

S – алкоголь, наркотик яисә башка төрле токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә бирелә торган субвенция күләме;

V – муниципаль бирем белән билгеләнгән j муниципаль хезмәт күрсәтү күләме;

D – Казан шәһәре Башкарма комитетының норматив-хокукый акты нигезендә исәпләнгән хезмәт өчен түләүгә Казан шәһәре бюджетыннан бирелә торган өстәмә бюджет ассигнованиеләре.

## III. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау тәртибе

3.1. Чираттагы финанс елына һәм план чорларына хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан чираттагы финанс елына һәм план чорларына җиткерелгән лимитлар күләме чикләрендә раслана.

3.2. Муниципаль биремне үтәү срогы дәвамында Тәртип нигезендә билгеләнә торган норматив чыгымнарны үзгәртү норматив хокукый актларга (Учреждениенең эшләр башкаруга турыдан-туры бәйле хезмәткәрләренә (аерым категория хезмәткәрләренә) түләүләр күләмен дә билгели торган) муниципаль бирем үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү күләмен үзгәртүгә китерә торган үзгәрешләр кертелгән очракта башкарыла (кирәк булганда).

---